| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ<br>ВЕТЕРИНАРИИ<br>КАБИНЕТА МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР<br>КАБИНЕТЫНЫҢ<br>БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.12.2019 Казан шәһәре № 195-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруда дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы 165-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2015 елның 19 гыйнварындагы 6-п номерлы, 2015 елның 15 декабрендәге 534-п номерлы, 2016 елның 12 июлендәге 257-п номерлы, 2016 елның 8 декабрендәге 513-п номерлы, 2019 елның 24 апрелендәге 51-од номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруда дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктның өченче абзацында «, Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 пунктта:

утыз алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм

муниципаль контроль органнары тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, басылып чыгару номеры: 0001201703210041);»;

кырык өченче абзацны төшереп калдырырга;

1.8 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасында:

унынчы-унөченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гадәттән тыш хәтәрлек категориясе өчен – елына бер тапкыр;

югары хәтәрлек категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

уртача хәтәрлек категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм биш елга кимендә бер тапкыр;

уртача хәтәрлек категориясе өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм сигез елга кимендә бер тапкыр.;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясы нигезендә үзләре турындагы белешмәләр кече һәм урта эшкуарлыкның бердәм реестрында теркәлгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашырганда планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3 нче бүлектә 1 нче таблицаның «Зарури таләпне билгеле торган норматив хокукый акт» графасының 6 нчы юлында Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны рәсмиләштерү эшен оештыру кагыйдәләрен һәм Ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны электрон рәвештә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 июлендәге 281 номерлы боерыгы» дигән сүзләрне Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны рәсмиләштерү эшен оештыру кагыйдәләрен, ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны электрон рәвештә рәсмиләштерү тәртибен һәм ветеринария буенча теркәлергә тиешле кәгазь документларны рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 27 декабрендәге 589 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче бүлектә 1 нче таблицаның «Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасының 8 нче юлында Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Ветеринариядә кулланыла торган наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлеген раслау турында» 2003 елның 29 декабрендәге 619 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә тикшерүдә тотылырга тиешле наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлекләрен

раслау турында» 1998 елның 30 июнендәге 681 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче бүлектә 1 нче таблицаның «Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасының 15 нче, 27 нче, 37 нче юлларында «Автомобиль транспортында йөк ташуның гомуми кагыйдәләре (РСФСР Автотранспорт министрлыгы тарафыннан 1971 елның 30 июлендә расланган)» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспортында йөк ташу кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 15 апрелендәге 272 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга; «Россия Федерациясе Элемтә юллары министрлыгының «Тиз бозыла торган йөкләрне тимер юл транспортында ташу кагыйдәләрен раслау турында» 2003 елның 18 июнендәге 37 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Транспорт министрлыгының «Тиз бозыла торган йөкләрне тимер юл транспортында ташу кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 4 мартындагы 66 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче бүлектәге 2 нче таблицаның 6 нчы юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «1 нче номерлы формада ветеринария таныклыгы;<br>2 нче номерлы формада ветеринария таныклыгы;<br>3 нче номерлы формада ветеринария таныклыгы;<br>4 нче номерлы формада ветеринария белешмәсе | Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны рәсмиләштерү эшен оештыру кагыйдәләрен, ветеринария буенча теркәлергә тиешле документларны электрон рәвештә рәсмиләштерү тәртибен һәм ветеринария буенча теркәлергә тиешле кәгазь документларны рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 27 декабрендәге 589 номерлы боерыгы |

«;

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру, зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасының «Тикшерү уздыру» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 5.9.1 пункт өстәргә:

«5.9.1. Планлы тикшерү уздырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе тарафыннан эшләнә һәм раслана торган тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) кулланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү уздырылганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга белдерелә торган, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә зыян салыну куркынычы барлыкка килүгә, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычына юл куймау күзлегеннән

караганда үтәлеше аеруча әһәмиятле булган зарури таләпләргә кагылышлы сораулар була.»;

5.10 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә тегеп куя һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра. Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.»;

5.14 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерү уздыру, зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очракларын бетерү буенча чаралар күрү» административ процедурасының «Тикшерү уздыру» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 5.17.1 пункт өстәргә:

«5.17.1. Планлы күчмә тикшерү уздырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең вазыйфаи затлары әлеге Регламентның 5.9.1 пунктында бәян ителгән таләпләрне үтәп, тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга бурычлы.»;

5.23 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.33 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.44 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 593 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г. Хисаметдинов